СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423181, РТ, Новошешминский район, село Тубылгы Тау, ул.Молодежная, д.73,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423181,ТР, Яңа Чишмә районы, Тубылгы Тау авылы, Яшьләр урамы, 73

тел.:(8-84348)3-82-58,факс:(8-84348)3-82-44,Tub.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 25 нче августы № 32-115

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 16 марты 24-60 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы Президиумының «Реестрлар алып бару турында» 13.10.2016 № ПР-26-4 карарын исәпкә алып муниципаль норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, җирле үзидарә органнары кабул иткән норматив хокукый актларның норматив хокукый базасын камилләштерү, аларны исәпкә алуны унификацияләү һәм системалаштыру максатларында, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 16.03.2017 24-60 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә (Советның 19.03.2020 №64-146, 20.06.2023 №31-109 карарлары редакциясендә,) (алга таба - Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.4 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Реестрларга муниципаль норматив хокукый актлар турында түбәндәге өстәмә мәгълүматлар кертелергә тиеш:

рәсми басманың чыганагы һәм датасы турында;

дата күрсәтелгән хокукый экспертиза үткәрү турында;

прокурорлык реакциясе актлары турында;

регистрга җибәрү турында (порталда урнаштыру).»;

1.2. Нигезләмәнең № 1, № 2, № 3, № 4 кушымталарында «документка үзгәрешләр кертү (гамәлдән чыгару)» баганасын чыгарырга».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы

Ф.Ф. Исмәгыйлев